Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Советы

КАРАР №15

Югары Тегермәнлек авылы 2024 елның 25 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Советының "2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге бюджеты турында"гы карары хакында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсе 10 өлешенең 2 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 12, 14, 15 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Законының 22 маддәсе 8 өлешенең 2 пункты, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Уставының 19 маддәсе 2 өлешенең 3 пункты һәм 70, 71 маддәләре нигезендә ТР Балык Бистәсе муниципаль районы , Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

**1 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең 2025 елга бюджетының төп сыйфатламаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 4913,68 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4913,68 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 сум.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлегенең 2026 елга һәм 2027 елга бюджетының төп сыйфатламаларын расларга:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлегенең 2026 елга керемнең фаразланган гомуми күләме 5 67,50 мең сум. 2027 елга – 5391,20 мең сум;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлегенен 2026 елга бюджет чыгымнарының гомуми күләме 3567,6 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 84,19 мең сум, 2027 елга алар тиндәшле рәвештә 3737,8 мең сум һәм 176,52 мең сум;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлегенең 2026 елга бюджеты кытлыгы 0 сум, 2027 елга –0 сум.

3. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 1 кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2 маддә.

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлегенең 2026 елның 1 гыйнварына булган торышы буенча бурыч йөкләмәләре буенча эчке үзидарәлек бурычының югары чиген 0 сум, шул исәптән үзидарәлек гарантияләре буенча 0 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлегенең 2027 елның 1 гыйнварына булган торышы буенча бурыч йөкләмәләре буенча эчке үзидарәлек бурычының югары чиген 0 сум, шул исәптән үзидарәлек гарантияләре буенча 0 сум күләмендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлегенен 2028 елның 1 гыйнварына булган торышы буенча бурыч йөкләмәләре буенча эчке үзидарәлек бурычының югары чиген 0 сум, шул исәптән үзидарәлек гарантияләре буенча 0 сум күләмендә расларга.

**3 маддә.** Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегерменлек авыл җирлеге бюджетында керемнәрнең фаразланган күләмнәрен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына 2 кушымтага ярашлы рәвештә игътибарга алырга.

**4 маддә.**

1. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең идарәчелек (тармак) структурасына, бүлекләр һәм бүлекчәләре, максатчан маддәләре һәм чыгымнар төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләре бүленешен 3 кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына бюджет чыгымнарынын ведомство структурасын 4 кушымта нигезендә расларга.

**5 маддә.**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан 2025 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан алына торган муниципаль район составына керүче җирлекләр бюджетларына бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләү һәм башка бюджетара

трансфертлар биру вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен уртак финанслау максатларында авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр күләмен 3245,98 мең сум, 2026 елга 3457,50 мең сум, 2027 елга 3631,40 мең сум күләмендә расларга.

6 маддә.

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә башлангыч хәрби исәпне гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруга җирлекләр бюджетына Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләр күләмен 2025 елга 182,98 мең сум, 2026 елга 200,1 мең сум, 2027 елга 207,3 мең сум итеп расларга.

7 маддә.

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Түбән Тегермәнлек - авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2025 елда һәм 2026 һәм 2027 еллардагы план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә тәкъдим итәргә.

8 маддә.

1.Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

9 маддә.

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге исеменнән төзелгән товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен 2024 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар буенча төзелгән килешүләрнең калган суммасыннан артмаган күләмдә Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, 2025 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

10 маддә.

1. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

11 маддә.

1. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Түбән Тегермәнлек авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында:

-Югары Тегермәнлек авылы, Совет урамы, 72 А йорт;

һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Бистәсе муниципаль районы
Түбән Тегермәнлек авыл җирлеге Башлыгы М.Г.Мингарипов